Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты

КАРАРЫ

«22» январь 2019 ел № 11

Кадастр номеры 16: 45: 010120: 8
булган җир кишәрлегенә карата
планлаштыру һәм территорияне
межанлау проектын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьясы нигезендә,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Ленин урамындагы 193 нче күпфатирлы торак йортның фатир милекчеләре мәнфәгатьләрендә эш йөртүче Кочетков С.В. га үз акчалары хисабына Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, Ленин ур., 193 йорт адресы буенча урнашкан, 16:45:010120:8 кадастр номеры булган җир кишәрлегенә карата планлаштыру һәм территорияне межанлау проектын әзерләүгә керешергә. (1 нче кушымта).

2. «Әлмәт муниципаль районы һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р.Р.) территорияне планлаштыру документларын әзерләү һәм карап тоту тәртибе нигезендә әлеге тәкъдимне кабул итүне һәм карауны тәэмин итәргә.

3. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.


4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Мөхәммәтҗанов А.А. ка йөкләргә.

Шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Ф. Валеев

Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 22 январе 11 номерлы карары белән расланган 1 нче кушымта

Кадастр номеры 16:45:010120:8
булган җир кишәрлеге чикләре



Башкарма комитет җитәкчесенең
төзелеш буенча урынбасары А.А. Мөхәммәтҗанов